СОВЕТ НИЖНЕУСЛОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ТҮБӘН ОСЛАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

06.12.2021г.　　　　　　　　　　№2

с. Нижний Услон

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан  авыл җирлеге Түбән Ослан  авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Югары Ослан муниципаль районының Түбән Ослан  авыл җирлеге Түбән Ослан  авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән   балигъ булган һәр кешедән 2022 елда 4500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә риза буласызмы? " мәсьәләсе буенча 2021 елның 7 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

- төзелеш материаллары сатып алу һәм Красноармейская урамы буенча вак таш җәю

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашкан 28 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны   28 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен тавыш бирде 28 халык җыенында катнашучы; «Юк» позициясе өчен тавыш бирде  0  җыенда катнашучы

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге Түбән Ослан авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре дөрес дип танылды.

1. «Югары Ослан муниципаль районының Түбән Ослан авыл җирлеге Түбән Ослан авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, авыл җирлеге Башкарма комитеты карары белән билгеләнгән ташламалы категориядән тыш, балигъ булган һәр кешедән 2022 елда 4500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә риза буласызмы? " дигән   сорау буенча карарны таныргa:

- төзелеш материаллары сатып алу һәм Красноармейская урамы буенча вак таш җәю

3. Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге Түбән Ослан авыл халык җыенының нәтиҗәләрен Түбән Ослан авыл җирлегенең

мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны җибәрергә.

Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгы урынбасары Казанцев С.А.